ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2019 Казан шәһәре № 3-21/э

Татарстан Республикасында халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләштерелгән категорияләренә 2020 елга электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) киметүле коэффициентлар куллану хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында халык өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметүле 0,7 коэффициентының кулланылуын билгеләргә:

1.1. шәһәр торак пунктларында, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган йортларда яшәүчеләр;

1.2. авыл торак пунктларында яшәүчеләр өчен.

2. 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән аерым категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметүле коэффициентларны шушы карар кушымтасына туры китереп кулланылуын билгеләргә.

3. 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында халыкка тиңләштерелгән кулланучылар өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата, әлеге

карарның 2 пунктында күрсәтелгән кулланучылардан тыш, киметүле коэффициентның кулланылмавын билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 3-21/э карарына кушымта

# Татарстан Республикасында кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән категорияләре өчен 2020 елга электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) киметүле коэффициентлар

| т/с | Кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән категорияләре | Киметүле коэффициентлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I яртыеллык | | II яртыеллык | |
| | | шәһәр торак пунктларында урнашкан, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган торакларда торучылар | авыл торак пунктларында торучылар | шәһәр торак пунктларында урнашкан, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган торакларда торучылар | авыл торак пунктларында торучылар |
| 1 | Коммерциясез бакчачылык ширкәтләре һәм коммерциясез яшелчәчелек ширкәтләре. Электр энергиясен (егәрлеген) алга таба халыкка һәм аңа тиңләштерелгән, кулланучыларның әлеге пунктта күрсәтелгән категорияләренә сату максатларында сатып алучы гарантияле тщэминатчылар, энергия сатучы, энрегия белән тәэмин итүче оешмалар. <1> | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 0,7 |
| 2 | Мәхәллә кешеләре хисабына | – | 0,7 | – | 0,7 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | яшәүче дини оешмалар.<br>Электр энергиясен (егәрлеген) алга таба халыкка һәм аңа тиңләштерелгән, кулланучыларның әлеге пунктта күрсәтелгән категорияләренә сату максатларында сатып алучы гарантияле тәэминатчылар, энергия сатучы, энрегия белән тәэмин итүче оешмалар. <1> | | | | |

<1> Электр энергиясен (егәрлеген) алга таба халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләштерелгән категорияләренә караган тиешле кулланучы категорияләре булган очракта, халык һәм аңа тиңләштерелгән кулланучы категорияләре тарафыннан фактта куллану күләмнәрендә һәм гражданнарның коммуналь-көнкүреш ихтыяҗларында файдалану максатларында уртак файдаланыла торган урыннарга тотылган һәм коммерцияле (һөнәри) эшчәнлек башкару өчен кулланылмый торган электр энергиясе күләмнәрендә сату максатларында сатып алучы гарантияле тәэминатчылар, энергия сатучы, энергия белән тәэмин итүче оешмалар.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге